ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**__28.09.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ __2490________**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрү тәртибе турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Зеленодольск шәһәр прокуратурасы белән тиешле хезмәттәшлек итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актларын кабул иткәндә гамәлдәге закон нормаларын профилактик ачыклау һәм бозуга юл куймау өлешендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәр прокуратурасына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын җибәрү тәртибен кушымтада каралганча расларга:
2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 28 сентябрендәге
2490 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрү тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актларын кабул иткәндә гамәлдәге законнар нормаларын бозуны профилактик яктан ачыклау һәм булдырмау максатларында эшләнгән.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый актлары проектлары астында түбәндәге норматив характердагы актлар проектлары аңлашыла:

-билгеләнгән тәртиптә нәшер ителгәннәр;

-вәкаләтле хокук органы тарафыннан нәшер ителгәннәр;

-актта хокукый нормаларда (тәртип кагыйдәләрендә)булган:

- билгесез төркем затлары өчен мәҗбүри ;
- берничә тапкыр куллануга исәпләнгән;
- иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салуга яки гамәлдәге хокук мөнәсәбәтләрен үзгәртүгә яки туктатуга юнәлтелгән.

3. Барлык норматив хокукый актлар проектлары Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының документлар әйләнеше һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенә кергәннән соң (алга таба бүлек) 3 көн эчендә экспертиза үткәрү өчен Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрелә.

4. Проектлар Зеленодольск шәһәр прокуратурасына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беркетелгән хаты белән, шулай ук zel.prok@tatar.ru адресы буенча электрон почта аша (яки Зеленодольск шәһәр прокуратурасы белән язмача килешү буенча электрон почтаның башка адресы аша)җибәрелә .

5. Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрелгән норматив хокукый актлар проектлары, шулай ук алар буенча алынган бәяләмәләр исәпкә алу журналында теркәлә һәм түбәндәге мәгълүмат кертелә:

- норматив хокукый акт проектының исеме;

-норматив хокукый акт проектының бүлеккә керү датасы

- инициатор (эшләүче) турында белешмәләр;

- норматив хокукый акт проекты бәяләмәсен алу өчен Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрү датасы;

- Зеленодольск шәһәр прокуратурасыннан җавап керү турында белешмәләр.

6. Әлеге юнәлештә эшчәнлекне оптимальләштерү, мәгълүмат белән нәтиҗәле оператив алмашуны җайга салу максатларында бүлек норматив

хокукый актларның исәпкә алынган проектларын түбәндәге юллар белән тикшерә:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектлары реестрына экспертиза ясау өчен әлеге тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрү;

- Зеленодольск шәһәр прокуратурасыннан (килешү буенча) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының экспертизага кергән норматив хокукый актлар проектлары реестры алу.

Тикшерү электрон документ әйләнеше (электрон почта) юлы белән узган кварталдан соң айның бишенче көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

7. Зеленодольск шәһәр прокуратурасына норматив хокукый актлар проектларын җибәрү белән бәйле эш алып бару бурычлары, вазыйфаи инструкция нигезендә оештыру-күрсәтмә документлары өчен җаваплы бүлек хезмәткәренә йөкләнә ( орфографияне тикшерү, дөрес рәсмиләштерү һәм җитәкче тарафыннан имзаланганнан соң документны теркәү).

Зеленодольск шәһәр прокуратурасына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын җибәрү тәртибенә
кушымта

(Форма)

## Зеленодольск шәһәр прокуратурасына экспертизага җибәрелгән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектлары реестры

| № т/б | Норматив хокукый акт проекты исеме | Зеленодольск шәһәр прокуратурасына җибәрелгән дата | Проектны җибәргән ЗМР Советы аппаратының документлар әйләнеше һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге вазифаи заты __________ | Зеленодольск шәһәр прокуратурасы бәяләмәсе (дата, документ № ) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |